ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

---

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

03.02.2020 Казан ш. № 6

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2013 елның 4 декабрендәге 94 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең норматив хокукый актын федераль законнарга яраштыру максатларында,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2013 елның 4 декабрендәге 94 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2016 елның 26 июлендәге 48 номерлы, 2017 елның 06 апрелендәге 21 номерлы, 2018 елның 26 гыйнварындагы 9 номерлы, 2018 елның 1 октябрендәге 89 номерлы, 2019 елның 1 мартындагы 22 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең хокук идарәсе юридик бүлегенә бу боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең җыелма анализ бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелеш күзәтчелеге
инспекциясенең 2020 елның 3
февралендәге 6 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2013 елның 4 декабрендәге 94 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.2 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына тиешле мәгълүматны кертү, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда эшләрне формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2006 елның 26 декабрендәге 1130 номерлы боерыгы нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда эшләрне формалаштыру һәм алып бару Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

1.2.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) вазыйфаи зат – Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) боерыгы белән законнар нигезендә билгеле бер капиталь төзелеш объектында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру, шул исәптән Регламентта каралган гамәлләрне тиешенчә һәм үз вакытында башкару өчен җаваплы зат итеп билгеләнгән Инспекциянең территориаль органы хезмәткәре;»;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №1, 1 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Арбитраж процессуаль кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №30, 3012 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ ШрК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1, 16 статья, кертелгән

үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Хәтәр җитештерү объектларының сәнәгый куркынычсызлыгы турында» 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1997, №30, 3588 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, №14, 1650 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 73-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №26, 2519 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Техник җайга салу турында» 2002 елның 27 декабрендәге 184-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №52, 5140 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2004, №31, 3215 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – № 59-ФЗ федераль закон)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №19, 2060 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 30, 3579 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, №52, 6249 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 261-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, №48, 5711 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 384-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №1, 5 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №1, 26 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеге турында» 2006 елның 1 февралендәге 54 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 54 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 7, 774 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны һәм капиталь төзекләндерүне гамәлгә ашырганда төзелеш контролен уздыру тәртибе турында» 2010 елның 21 июнендәге 468 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №26, 3365 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Куллану нәтиҗәсендә «Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» федераль законы таләпләренең үтәлүе зарури нигездә тәэмин ителә торган илкүләм стандартлар һәм кагыйдәләр җыелмалары (мондый стандартларның һәм кагыйдәләр җыелмаларының өлешләре) исемлеген раслау турында» 2014 елның 26 декабрендәге 1521 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №2, 465 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №19, 2825 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016 № 17, 2418 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда хәтәр юнәлеш алымын куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 806 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, №35, 5326 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10

февралендәге 166 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, №8, 1239 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, №18, 2647 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, капиталь төзекләндергәндә башкару документлары составына һәм аны алып бару тәртибенә карата таләпләрне һәм эшләрне, конструкцияләрне, инженер-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен таныклау актларына белдерелә торган таләпләрне раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2006 елның 26 декабрендәге 1128 номерлы боерыгы (алга таба – 2006 елның 26 декабрендәге 1128 номерлы Ростехнадзор боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2007, №13, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда тикшерүләр уздыру һәм төзелгән, үзгәртеп корылган, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектларының техник регламентлардагы, башка норматив хокукый актлардагы, проект документларындагы таләпләргә (нормаларга һәм кагыйдәләргә) ярашуы турында бәяләмәләр бирү тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2006 елның 26 декабрендәге 1129 номерлы боерыгы (алга таба – 2006 елның 26 декабрендәге 1129 номерлы Ростехнадзор боерыгы)(Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2007, №15, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда эшләрне формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2006 елның 26 декабрендәге 1130 номерлы боерыгы (алга таба – 2006 елның 26 декабрендәге 1130 номерлы Ростехнадзор боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2007, №13, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, капиталь төзекләндергәндә эшләр башкаруны исәпкә алу буенча гомуми һәм (яисә) махсус журнал алып бару тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2007 елның 12 гыйнварындагы 7 номерлы боерыгы (алга таба – 2007 елның 12 гыйнварындагы 7 номерлы Ростехнадзор боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2007, №14, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик

затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзелешкә рөхсәт формасын һәм объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт формасын раслау турында» 2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (http://www.pravo.gov.ru), 2015, 13 апрель, басылып чыгу номеры: 0001201504130006);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы формасын һәм аны тутыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 25 апрелендәге 741/пр номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru) 2017, 31 май, басылып чыгу номеры: 0001201705310041);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Үзирекле төзелешне ачыклау турында хәбәр формасын һәм үзирекле төзелеш билгеләре булуын раслый торган документлар исемлеген раслау турында» 2019 елның 19 мартындагы 169/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 2019 елның 19 мартындагы 169/пр номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2019, 18 апрель, басылып чыгу номеры: 0001201904180019);

Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның «Кулланган вакытта «Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре ирекле нигездә тәэмин ителә торган стандартлаштыру өлкәсендә документлар исемлеген раслау турында» 2019 елның 17 апрелендәге 831 номерлы боерыгы («Ценообразование и сметное нормирование в строительстве» журналы, июнь, 2019 ел, №6);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы карары (алга таба – 622 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, №43, 1707 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда капиталь төзелеш объектларының инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә контрольлек оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 1 сентябрендәге 745 номерлы карары (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU, 2018, 3 сентябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан

Республикасында хәтәрлеккә юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре исемлеген раслау турында» 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы карары (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми интернет-порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU, 2018, 3 октябрь);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеше өчен төзелешкә рөхсәтләр бирү таләп ителми торган объектлар исемлеген раслау турында» 2011 елның 24 июнендәге 1038-р номерлы боерыгы («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2011, №33, 1617 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге гамәлгә ашырыла:

а) РФ ШрК 49 статьясы нигезендә, проект документлары экспертизага тиешле капиталь төзелеш объектлары төзелгәндә, РФ ШрК 54 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән объектлардан тыш;

б) капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп корганда, шул исәптән төбәк һәм җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклау буенча мондый объектларның корылма һәм башка төр ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламаларына кагыла торган эшләр уздырылганда, әгәр капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп коруга, шул исәптән мәдәни мирас объектларын саклау буенча әлеге эшләрне башкаруның проект документлары РФ ШрК 49 статьясы нигезендә экспертизага тиешле булса, РФ ШрК 54 статьясының 3 өлешендә күрсәтелгәннәрдән тыш;

в) әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелмәгән капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, шулай ук РФ ШрК 54 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган нигезләр буенча төзү, үзгәртеп кору эшләре тәмамланган шундый капиталь төзелеш объектларына карата (күрсәтелгән эшләр тәмамланганнан соң объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт алынган очрактан тыш).»;

1.6 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге предметы булып әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән объектларны тикшерү тора:»;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору барышында эшләр башкаруның һәм кулланыла торган төзелеш материалларының туры килү-килмәве, шулай ук мондый эшләр нәтиҗәләренең РФ ШрК 48 статьясындагы 15, 15.2 һәм 15.3 өлешләре нигезендә расланган проект документларының (РФ ШрК 49 статьясындагы 3.8 һәм 3.9 өлешләре нигезендә проект документациясенә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) һәм (яисә) мәгълүмат моделенең (мәгълүмат моделен формалаштыру һәм алып бару РФ ШрК таләпләре нигезендә мәҗбүри булган очракта) таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә (энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре кагылмый торган капиталь

төзелеш объектларыннан тыш) һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин ителү таләпләренә туры килүен;»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыручы зат (алга таба – төзелешне гамәлгә ашыручы зат) төзүче оешма яисә шәхси эшкуар яисә төзелеш буенча подряд килешүен төзегән юридик зат була ала. Төзелешне гамәлгә ашыручы зат күрсәтелгән эшләр барышында проект документлары, техник регламентлар, куркынычсызлык техникасы таләпләре үтәлүен тәэмин итә һәм башкарылган эшләрнең сыйфаты һәм аларның проект документлары таләпләренә һәм (яки) мәгълүмат моделенә туры килүе өчен җаваплы була (мәгълүмат моделен формалаштыру һәм алып бару РФ ШрК таләпләре нигезендә мәҗбүри булган очракта).;»;

сигезенче, тугызынчы абзацларны гамәлдән чыккан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле $1.6^1$ һәм $1.6^2$ пунктларны өстәргә:

«$1.6^1$. Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата дәүләт төзелеш күзәтчелеге предметы булып, капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәттә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерү тора, ә капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору өчен төзелешкә рөхсәт бирү таләп ителмәсә, – капиталь төзелеш объектлары параметрларының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән билгеләнгән рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору объектларының чик параметрларына һәм капиталь төзелеш объектларының РФ ШрК, башка федераль законнарда билгеләнгән параметрларына туры килүен тикшерү тора.

$1.6^2$. Инспекция тарафыннан уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча төзелешкә рөхсәт алмыйча капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору факты (капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору өчен мондый рөхсәтне алу таләп ителмәгән очраклардан тыш) яки капиталь төзелеш объектының төзелешкә бирелгән рөхсәттә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү факты ачыкланган очракта, әгәр капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору өчен төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәгән очракта капиталь төзелеш объектының капиталь төзелеш объектларын рөхсәтле төзү, үзгәртеп коруның җирдән файдалану, төзелеш кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән чик параметрларына туры килмәү яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата РФ ШрК, башка федераль законнарда билгеләнгән зарури таләпләргә туры килмәү факты ачыкланган очракта, Инспекция тикшерүне тәмамлаган көннән башлап 5 эш көненнән соңга калмыйча тиешле фактны раслый торган документларны теркәп, үзирекле төзелешне ачыклау турындагы хәбәрне мондый капиталь төзелеш объекты урнашкан җирлекнең, шәһәр округының җирле үзидарә органына яки, капиталь төзелеш объекты җирлекара территориядә урнашкан очракта, муниципаль районның җирле үзидарә органына җибәрә. Үзирекле төзелешне ачыклау турында хәбәр формасы, шулай ук үзирекле төзелеш билгеләре булуын раслый торган

документлар исемлеге Россия Төзелеш министрлыгының 2019 елның 19 мартындагы 169/пр номерлы боерыгы белән билгеләнгән.»;

1.7 пунктның 4 пунктчасында «техник регламентлар, башка норматив хокукый актлар» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.12 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.12. Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән объектларга карата дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) 294-ФЗ номерлы федераль законның 13.3 статьясына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карарына ярашлы рәвештә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

түбәндәге эчтәлекле 1.13 пункт өстәргә:

«1.13. Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) 3 нөсхәдә рәсмиләштерелгән тикшерү акты;

2) 294-ФЗ номерлы федераль законның 13.3 статьясына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карарына ярашлы рәвештә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

3) зарури таләпләр бозылуны ачыклаган очракта Административ хокук бозулар турында РФ кодексында каралган административ хокук бозу турында беркетмә.

4) тиешле фактны раслый торган документларны теркәп, үзирекле төзелешне ачыклау турында хәбәр.»;

2 бүлектә:

2.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.11. Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән объектларга карата дәүләт функциясен үтәү инспекция тарафыннан эшләр башлану турында хәбәр алынганнан алып, төзүче оешмага яисә техник заказчыга туры килү турында бәяләмә бирелгән датага кадәр гамәлгә ашырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле $2.11^1$ пункт өстәргә:

«$2.11^1$. Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата дәүләт функциясен үтәү РФ ШрК 54 статьясындагы 2 пунктның «б» пунктчасында, 5 өлешенең 3 пунктындагы «б» яки «в» пунктчаларында каралган нигезләр килеп җиткән көннән башлап яисә әлеге Регламентның 1.4 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелмәгән капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда капиталь төзелеш объектларын рөхсәтле төзү, үзгәртеп коруның җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләрендә, территорияләрне планлаштыру документларында билгеләнгән чик параметрлары яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата РФ ШрК, башка федераль законнарда билгеләнгән зарури таләпләрнең бозылуы турында гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан (дәүләт күзәтчелеге органының вазыйфаи

затларыннан), җирле үзидарә органнарыннан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар алынган датадан башлап һәм, җитешсезлекләр ачыкланган очракта, өч нөсхәдә тикшерү акты төзелгән һәм мондый капиталь төзелеш объекты урнашкан урын буенча җирлекнең, шәһәр округының җирле үзидарә органына җибәрелгән датадага кадәр яки, капиталь төзелеш объекты җирлекара территориядә булган очракта, – муниципаль районның җирле үзидарә органына тикшерү актының өченче нөсхәсе, шулай ук тикшерү уздыру процессында төзелгән яки алынган документлар һәм, тиешле фактны раслый торган документларны теркәп, үзирекле төзелеш ачыклануы турындагы хәбәр җибәрелгән датага кадәр гамәлгә ашырыла.»;

2.14 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән объектларга карата тикшерүләр үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:»;

түбәндәге эчтәлекле 2.14[1] пункт өстәргә:

«2.14[1]. Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата тикшерүләр үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әгәр мондый бозулар кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләт мөлкәтенә яки муниципаль мөлкәткә куркыныч тудырса яки мондый зыян салынуга китереп чыгарса, капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору процессында барлыкка килгән авария, техник регламентларны, бүтән норматив хокукый актларны һәм проект документациясен бозу фактлары, шул исәптән кулланыла торган төзелеш материалларына карата зарури таләпләрнең бозылуы турында Инспекциягә гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, РФ ШрК 53 статьясының 3 өлеше нигезендә төзелешне гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан җибәрелүче хәбәрләрне дә кертеп, дәүләт хакимияте органнарыннан (дәүләт күзәтчелеге органнары вазыйфаи затларыннан), җирле үзидарә органнарыннан, РФ ШрК 53 статьясының 3 өлеше нигезендә төзелешне гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан җибәрелүче хәбәрләрне дә кертеп, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматлар килгәндә;

2) юридик затның, шәхси эшкуарның Инспекция тарафыннан элек бирелгән ачыкланган зарури таләпләрне бозуны юкка чыгару турындагы күрсәтмәне үтәү чоры бетү;

3) Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләренә туры китереп яисә прокурорның прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләбе нигезендә чыгарылган тикшерү уздыру турында боерыгы (күрсәтмәсе) булганда;

4) әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелмәгән капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда җир корылышы һәм төзелеш кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләрнең, территорияне

планлаштыру документларында капиталь төзелеш объектларын рөхсәтле төзү, үзгәртеп кору буенча билгеләнгән чик параметрларның яки РФ ШрК, башка федераль законнарда капиталь тезелеш объектлары параметрларына карата билгеләнгән зарури таләпләрнең бозылуы турында гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан (дәүләт күзәтчелеге органы вазыйфаи затларыннан), җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат алынганда.»;

«Дәүләт төзелеш күзәтчелеге өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозган өчен юридик затларның, шәхси эшкуарларның җаваплылыгы» бүлекчәсе атамасында «шәхси эшкуарларның» сүзләреннән соң «, шәхси эшкуар булып тормаган физик затларның» сүзләрен өстәргә;

2.16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.16. Нигезсез рәвештә тикшерүләрне уздыруга каршы килә торган, тикшерүләрне үткәрүдән читләшә торган юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлары яки юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшкуар булып тормаган физик затлар (алга таба – физик затлар) Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.»;

3 бүлектә:

атамасында «шәхси эшкуарларга» сүзләреннән соң «, физик затларга» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктта «шәхси эшкуарларга» сүзләреннән соң «, физик затларга» сүзләрен өстәргә;

2 нче таблицада:

«Зарури таләп тәгъбирләнеше» графасында:

15 пунктта «документациясе» сүзеннән соң «һәм (яки) мәгълүмат моделе (мәгълүмат моделен формалаштыру һәм алып бару РФ ШрК таләпләре нигезендә мәҗбүри булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Проектлау йөкләмәсе, проект документлары һәм (яки) мәгълүмат моделе (мәгълүмат моделен формалаштыру һәм алып бару РФ ШрК таләпләре нигезендә мәҗбүри булган очракта) капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата төзелешкә рөхсәт алу өчен җир кишәрлегенең шәһәр төзү планы бирелгән датага билгеләнгән таләпләр, җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану таләпләренә, Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләр, техник регламентларның таләпләре нигезендә капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору һәм бу вакытта өченче затлар, әйләнә-тирә мохит өчен эшләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, хезмәт куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү, мәдәни мирас объектлары саклануын тәэмин итү»;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Проект документларын раслау, шулай ук РФ ШрК 49 статьясының 3.8 һәм 3.9 өлешләре нигезендә аңа кертелгән үзгәрешләрне раслау»;

25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. РФ ШрК 48 статьясындагы 15.2 һәм 15.3 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, проект документларын һәм инженерлык эзләнүләрен

экспертизага җибәрү»;

түбәндәге эчтәлекле 33-36 пунктлар белән тулыландырырга:

| | | |
|---|---|---|
| | «33. РФ ШрК 49 статьясындагы 3.8 һәм 3.9 өлешләре нигезендә проект документларына кертелгән үзгәрешләрне РФ ШрК 48 статьясындагы 15.2 һәм 15.3 өлешләре нигезендә мондый үзгәрешләр кертелгән көннән башлап ун эш көне узганчы Инспекциягә җибәрү | РФ ШрК 52 статьясындагы 5.2 өлеше |
| Төзүче оешма (әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата) | 34. Төзелешкә рөхсәт булу (капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору өчен төзелешкә рөхсәт бирү таләп ителсә) | РФ ШрК 51 статьясының 2 өлеше; Россия Төзелеш министрлыгының 2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы боерыгы |
| | 35. Капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәттә күрсәтелгән таләпләргә туры килүе (әгәр капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору өчен төзелешкә рөхсәт бирү таләп ителсә) | РФ ШрК 51 статьясының 2 өлеше; Россия Төзелеш министрлыгының 2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы боерыгы |
| | 36. Капиталь төзелеш объектлары параметрларының капиталь төзелеш объектларын рөхсәтле төзү, үзгәртеп коруның җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән чик параметрларына һәм капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата РФ ШрК, башка федераль законнарда билгеләнгән зарури таләпләргә туры килүе (әгәр капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору өчен төзелешкә рөхсәт бирү таләп ителмәсә) | РФ ШрК 51.1 статьясының 13 өлеше»; |

4 бүлектә:

исемендә «эшкуар» сүзеннән соң «, физик зат» сүзләрен өстәргә;

беренче абзацта «шәхси эшкуарлар» сүзләреннән соң «, физик зат» сүзләрен өстәргә;

5 бүлектә:

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Дәүләт төзелеш контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- дәүләт төзелеш күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыруга әзерләү;
- капиталь төзелеш объектын тикшерү әзерләү һәм уздыру;
- тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;
- ачыкланган бозуларны бетерү буенча чаралар күрү;
- төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү;
- әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерүне гамәлгә ашыру.

Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыруның блок-схемасы әлеге Регламентка 2 нче, $2^1$ кушымталарында китерелә.

Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда дәүләт функциясен үтәүне туктатып тору рөхсәт ителә.»;

5.7.1 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Капиталь төзелешнең ике һәм аннан күбрәк объектын төзүгә рөхсәт бирелгән очракта, хәтәрлек категорияләре һәм тикшерүләр саны капиталь төзелешнең һәр объектына карата аерым билгеләнә.»;

5.9 пунктның икенче абзацында «техник регламентлар, башка норматив хокукый актлар» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.13. Әлеге Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән фактлар булган очракта, вазыйфаи зат (төркем җитәкчесе):

- әлеге Регламентның 8 нче кушымтасына туры китерелгән форма буенча тикшерү уздыру турында күрсәтмә проектын әзерли;
- аны бүлек башлыгы, территориаль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) белән килештерә;
- күрсәтмә проектын имза салу өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) юллый.

Тикшерүдә катнашучы вазыйфаи затларны алмаштыру, аны уздыру срокларын (башлау һәм тәмамлау даталарын), тикшерү предметын яки төрен үзгәртү тикшерү уздыру турында күрсәтмәгә үзгәрешләр кертү турында күрсәтмә белән рәсмиләштерелә.

Тикшерү уздыру турында күрсәтмәдә өстәмә рәвештә үзенә карата контрольлек буенча чаралар уздыруы планлаштырылган капиталь төзелеш объектының атамасы һәм урнашкан урыны күрсәтелә.

Үтәлү вакыты: күрсәтмә әзерләү һәм имзалау – тикшерү башланырга кимендә дүрт эш көне алдан.

Гамәлнең нәтиҗәсе: тикшерү уздыру турында күрсәтмә.

Әлеге Регламентның 2.14 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез

буенча юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып тикшерү уздыру Инспекция тарафыннан 294-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясындагы 12 өлешендә билгеләнгән тәртиптә прокуратура органына белдереп, кичекмәстән үткәрелергә мөмкин.

Үтәлү вакыты – кичекмәстән.

Гамәлнең нәтиҗәсе: тикшерү үткәрү турында күрсәтмә, планнан тыш тикшерү билгеләү турында дәлилләнгән күрсәтмә, күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына гариза, аңа теркәлә торган документлар.»;

5.28 пунктның икенче абзацында «техник регламентлар, башка норматив хокукый актлар» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.32 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.32. Капиталь төзелеш объектларында башкарыла торган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына (эшләнмәләргә) тикшеренүләр, лаборатор һәм/ки башка төрле сынаулар уздыру белән бергә туры килә торган тикшерүләрне оештырганда, Инспекциянең территориаль органнары тикшерүләр программалары кысаларында, шулай ук гамәлдәге законнарга туры китереп рәсмиләштерелгән хәбәрләр, мөрәҗәгатьләр яки башка төрле рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә контрольлек буенча чаралар барашыныда алынган белешмәләрнең объектив, төгәл булуын тәэмин итү һәм аларның проект чишелешләренә туры килүен билгеләү өчен тикшеренүләр уздыруны күзәтү буенча территориаль органны җәлеп итә.

5.42 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.42. Җитешсезлекләр ачыкланган очракта, күрсәтмәдә РФ ШрК статьяларына (пунктларына, статьялары өлешләренә), таләпләре бозылган проект документлары бүлекләренә (битләренә) сылтама күрсәтеп, җитешсезлекләрнең тасвирламасы, характеры, конкрет төре күрсәтелә, шулай ук капиталь төзелеш объектының конструктив һәм башка төр үзенчәлекләрен исәпкә алып, ачыкланган бозуларны бетерү вакыты билгеләнә.»;

5.56 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.56. Әлеге Регламентның 5.34-5.36, 5.38 пунктларына туры китереп, төзелеп беткән объектны тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерә.

Җаваплы башкаручы төзелеп беткән объектны тикшерү актын ике нөсхәдә рәсмиләштерә (бер нөсхәсе төзүче оешмага (техник заказчыга) бирелә, икенче нөсхәсе Инспекция эшендә кала), ул төзелеп беткән объектка тикшерү уздырган вазыйфаи затлар тарафыннан имзалана.

Тикшерү барышында зарури таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы:

- тикшерү актында барлык бозуларны да терки;

- әлеге Регламентның 5.41-5.45 пунктларында каралган тәртиптә бозуларны бетерү турында төзүче оешмага яисә техник заказчыга күрсәтмә төзи һәм бирә;

- әлеге Регламентның 5.46-5.50 пунктлары нигезендә ачыкланган зарури таләпләр бозылу фактына тикшерү уздыра.

Төзелеп беткән объектны ачыкланган җитешсезлекләре белән тикшерү акты, төзүче оешма яки техник заказчы Ярашлылык турында бәяләмә бирүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, Ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булып тора.

Төзелеп беткән объектны тикшерү барышында ачыкланган зарури таләпләр бозылуның ачыкланган очракларын бетергәннән соң төзүче оешма (техник заказчы) әлеге Регламентның 5.46 пунктының 2 пунктчасында, 5.52 пунктында күрсәтелгән гамәлләрне башкара.

Җаваплы затлар әлеге Регламентның 5.53-5.56 пунктлары нигезендә административ гамәлләр башкара.»;

түбәндәге эчтәлекле бүлек өстәргә:

«Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерүне гамәлгә ашыру» административ процедурасы

5.59. Әлеге Регламентның 2.14[1] пунктында күрсәтелгән факт булуы административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

5.60. Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерүне гамәлгә ашыру түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерүне оештыру һәм әзерләү;
- әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерүне әзерләү һәм уздыру;
- әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерүне оештыру һәм әзерләү

5.61. Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерүне оештыру һәм гамәлгә ашыру барышында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

- мөрәҗәгатьне кабул итү, теркәү, карау;
- күзәтчелек эшен формалаштыру.

Мөрәҗәгатьне кабул итү, теркәү, карау

5.62. АМСЭД администраторы Инспекциягә кергән, әлеге Регламентның 2.14[1] пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне (гаризаны яки мәгълүматны) терки һәм аны Инспекция башлыгы исеменә җибәрә. Инспекция башлыгы резолюциясе алынганнан соң, мөрәҗәгать вазыйфаи затка карап тикшерү өчен җибәрелә.

Үтәлү вакыты: Инспекциягә мөрәҗәгать килгән көнне.

Гамәлнең нәтиҗәсе: АМСЭД администраторы тарафыннан теркәлгән, вазыйфаи затка карау өчен җибәрелгән мөрәҗәгать.

5.63. Мөрәҗәгать алынганнан соң вазыйфаи зат мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән мәсьәләләрнең дәүләт төзелеш күзәтчелеге предметына керү-кермәвен тикшерә.

Мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән мәсьәләләр дәүләт төзелеш күзәтчелеге предметына кермәсә, мөрәҗәгатькә мотивацияле җавап бирелә яисә, мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгатьнең башка адреска җибәрелүе турында хәбәр итеп, мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итүгә компетенцияле булган тиешле органга яки тиешле вазыйфаи затка җибәрелә.

Кирәк булганда мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән мәгълүматка алдан тикшерү гамәлгә ашырыла.

Вазыйфаи зат тарафыннан килгән мәгълүматка беренчел тикшерү үткәрү барышында гаризаны һәм мөрәҗәгатьне җибәргән, мәгълүматлар җиткергән затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар (шул исәптән телдән тәртиптә) соратып алу буенча чаралар күрелә, юридик затның, шәхси эшкуарның Инспекциядә булган документлары карап тикшерелә, зарурлык булганда, юридик зат, шәхси эшкуар белән бәйләнешкә кермичә генә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүматлар тапшыру һәм дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы таләпләрен үтәү буенча бурычлар йөкләмичә генә контрольлек буенча чаралар үткәрелә. Беренчел тикшерү кысаларында юридик заттан, шәхси эшкуардан алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратылырга мөмкин, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка төрле документларны тапшыру мәҗбүри булып саналмый.

Гамәлнең нәтиҗәсе:

- дәүләт төзелеш күзәтчелеге предметына туры килү-килмәүгә билгеләнгән мөрәҗәгать;

- мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән мәсьәләләр дәүләт төзелеш күзәтчелеге предметына керми икән, мөрәҗәгатькә бирелгән нигезле җавап,

Үтәү вакыты: законда билгеләнгән срокларда.

## Күзәтчелек эшен формалаштыру

5.64. Мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән мәсьәләләр дәүләт төзелеш күзәтчелеге предметына кергән очракта, вазыйфаи зат Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1130 боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә күзәтчелек эшен формалаштыра һәм алып бара, аңа номер беркетә. Вазыйфаи зат күзәтчелек эшен кәгазьдә генә түгел, «Стройнадзор РТ» мәгълүмат-аналитика системасында да формалаштыру һәм алып бару өчен җавап бирә.

Территориаль орган җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары), территориаль орган бүлеге башлыгы күзәтчелек эшен оештыруга һәм алып баруга агымдагы контрольне башкара.

## Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерүне әзерләү һәм уздыру

5.65. Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерүне әзерләү һәм уздыру барышында

түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

- кирәк булган очракта ведомствоара һәм башка рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү, экспертларны (эксперт оешмаларын) җәлеп итү;
- тикшерү үткәрү турында күрсәтмә әзерләү;
- тикшерү үткәрү турында тикшерелүче затка хәбәр итү;
- күчмә тикшерү үткәрү.

Ведомствоара һәм башка мөрәҗәгатьләр җибәрү, кирәк булганда экспертларны (эксперт оешмаларын) җәлеп итү

5.66. Зарурлык булган очракта вазыйфаи зат тикшерү уздырыр алдыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында әлеге Регламентның 17 нче кушымтасында күрсәтелгән Исемлек буенча дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр яки тикшерү уздыру өчен кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүмат булган оешмаларга башка рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә; тикшерү уздырганда экспертларны (эксперт оешмаларын) җәлеп итүне оештыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 5.63 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында җибәрелгән ведомствоара һәм башка мөрәҗәгатьләр, җәлеп ителгән экспертлар (эксперт оешмалары).

5.67. Инспекция соратуы буенча документлар һәм (яки) мәгълүмат белән эш итүче дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә оешмалар тарафыннан автоматлаштырылган тәртиптә түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

рәсми мөрәҗәгатьне эшкәртү һәм сорала торган белешмәләрне эзләү;

сорала торган белешмәләрне формалаштыру, яки, сорала торган белешмәләр булмаган очракта, сәбәпләрен күрсәтеп, соралучы белешмәләрне баш тарту турында беледерү җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ гамәлләр законнарда билгеләнгән чорларда гамәлгә ашырыла.

Гамәлнең нәтиҗәсе: документлар (белешмәләр) яки белешмәләрне бирүдән баш тарту турында хәбәр.

Тикшерү үткәрү турында күрсәтмә әзерләү

5.68. Алдагы административ гамәлләр төгәлләнгәч һәм әлеге Регламентның $2.14^1$ пунктында күрсәтелгән фактлар булган очракта, вазыйфаи зат әлеге Регламентның 8 нче кушымтасына туры китерелгән форма буенча тикшерү уздыру турында күрсәтмә проектын әзерли; аны бүлек башлыгы (булган очракта), территориаль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) белән килештерә; күрсәтмә проектын имзалау өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) юллый.

Тикшерүдә катнашучы вазыйфаи затларны алмаштыру, аны уздыру срокларын (башлау һәм тәмамлау даталарын), тикшерү предметын яки төрен

үзгәртү тикшерү уздыру турында күрсәтмәгә үзгәрешләр кертү турында күрсәтмә белән рәсмиләштерелә.

Тикшерү уздыру турында күрсәтмәдә өстәмә рәвештә үзенә карата контрольлек буенча чаралар уздыруы планлаштырылган капиталь төзелеш объектының атамасы һәм урнашкан урыны күрсәтелә.

Үтәлү вакыты: күрсәтмәне әзерләү һәм имзалау – юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата тикшерү башланганчы дүрт эш көненнән дә соңга калмыйча, физик затларга карата тикшерү башланганчы бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Гамәлнең нәтиҗәсе: тикшерү уздыру турында күрсәтмә.

Әлеге Регламентның 2.14[1] пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып тикшерү уздыру Инспекция тарафыннан 294-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясындагы 12 өлешендә билгеләнгән тәртиптә прокуратура органына белдереп, кичекмәстән үткәрелергә мөмкин.

Үтәлү вакыты – кичекмәстән.

Гамәлнең нәтиҗәсе: тикшерү үткәрү турында күрсәтмә, планнан тыш тикшерү билгеләү турында дәлилләнгән күрсәтмә, күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына гариза, аңа теркәлә торган документлар.

5.69. Тикшерүне әлеге Регламентның 2.14[1] пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән фактлар нигезендә уздырган очракта, вазыйфаи зат урынга чыгып тикшерү уздыру турында күрсәтмә проекты белән бергә әлеге Регламентның 2.14[1] пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә планнан тыш тикшерү билгеләнүе турында Инспекциянең вазыйфаи затының нигезле йогынты актын әзерли.

Инспекциягә мөрәҗәгать итүченең затын билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук әлеге Регламентның 2.14[1] пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү уздыру турында Инспекция вазыйфаи затының нигезләнгән фогынты актында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләре булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алмый. Әгәр дә мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат, шушы Регламентның 2.14[1] пунктындагы 1 пунктчасы нигезендә планнан тыш тикшерү үткәрүнең нигезе була алса, Инспекциянең вазыйфаи заты, аның мөрәҗәгатьнең яки гаризаның авторына карата шикләре булганда, мөрәҗәгать итүче затны билгеләү буенча чаралар күрергә бурычлы. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, аларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан фәкать бердәм идентификацияләү һәм аутентификацияләү системасында мөрәҗәгать итүченең мәҗбүри авторлаштырылуын күздә тотучы мәгълүмат-коммуникация технологияләре чараларыннан файдаланып җибәрелгән булуы шарты белән генә, планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә ала.

Инспекция вазыйфаи затының әлеге Регламентның 2.14[1] пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү билгеләү

турындагы нигезле йогынты актында күрсәтелгән фактлар буенча мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматны карап тикшергәндә шуңа охшаш алданрак килгән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре, шулай ук тиешле юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата элегрәк уздырылган контрольлек чараларының нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

Инспекция башлыгы, Инспекция башлыгы урынбасары карары буенча, әгәр тиешле тикшерүне башлаганнан соң, аны оештыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланса, яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризада белә торып ялган белешмәләр булуы ачыкланса, тикшерү туктатыла.

Инспекция, әгәр гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә белә торып ялган белешмәләр күрсәтелсә, гражданиннан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшкуарлардан, аталган затлардан килгән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүгә бәйле рәвештә, Инспекция тарафыннан тотылган чыгымнарны түләттерү турында судка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Тикшерү үткәрү турында тикшерелүче затка хәбәр итү

5.70. Вазыйфаи зат тикшерү уздырылуы турында юридик зат булып торучы төзүче оешмага яки шәхси эшкуарга тикшерү уздыру турында Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе күчермәсен кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасын җибәрү юлы белән яки мөмкин булган башка ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса яки юридик зат, шәхси эшкуар, физик зат тарафыннан элегрәк Инспекциягә тапшырылган булса, юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ ярдәмендә хәбәр итә.

Үтәлү вакыты: тикшерүне үткәрә башлар алдыннан өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: төзүче оешмага тикшерү үткәрү турында хәбәр итү.

Әлеге Регламентның 2.14[1] пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча төзүче оешмага урынга чыгып тикшерү үткәреләчәге турында алдан хәбәр итү таләп ителми.

Төзүче – физик затка күчмә тикшерү үткәрү турында алдан хәбәр итү таләп ителми.

Күчмә тикшерү үткәрү

5.71. Тикшерү урынга чыгып тикшерү формасында үткәрелә.

5.72. Урынга чыгып тикшерү тикшерелә торган капиталь төзелеш объектының урнашу урыны буенча үткәрелә.

Әгәр шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының булмавына бәйле рәвештә, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекнең фактта башкарылмавына

бәйле рәвештә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының бүтән төрле, тикшерүне үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында урынга чыгып тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, тикшерү уздыруга вәкаләтле Инспекция вазыйфаи заты, аны үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы сәбәпләрне күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлегенең булмавы хакында акт төзи. Бу очракта Инспекция тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында актны төзегән көннән башлап өч ай дәвамында әлеге юридик затка, шәхси эшкуарга карата, юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә, урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү хакында карар кабул итәргә хокуклы.

Вазыйфаи затның мондый тикшерүләрне үткәрү буенча законлы эшчәнлегенә комачаулаган яки мондый тикшерүләрдән качкан, шулай ук тикшерүне үткәрү яки тәмамлау мөмкин булмаганлыгына китергән өчен Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.4.1 статьясында каралган административ хокук бозу турында беркетмә төзелә.

5.73. Контрольлек объектына килеп җиткәннән соң вазыйфаи затлар тикшерүне түбәндәгеләрдән башлый:

- хезмәт таныклыкларын күрсәтеп;

- төзүче оешма җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмә (башлык, башлык урынбасары мөһере белән таныкланган күрсәтмә күчермәсе кул куйдыртып тапшырыла) белән таныштырып;

- урынга чыгып тикшерү үткәрүче затларның вәкаләтләре белән таныштырып;

- урынга чыгып тикшерү уздыруның максатлары, бурычлары, нигезләре, контроль чаралары төрләре һәм күләме, экспертлар составы, күчмә тикшерүгә җәлеп ителә торган эксперт оешмалары вәкилләре, аны үткәрү вакыты һәм шартлары белән таныштырып.

5.74. Төзүче оешма таләбе буенча вазыйфаи зат, үзенең вәкаләтләрен раслау максатларында, Инспекция турында, шулай ук экспертлар, экспертлык оешмалары турында мәгълүмат бирергә бурычлы.

Төзүче оешма җитәкчесенең, вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең үтенече буенча, вазыйфаи зат тикшерелергә тиешле затларны әлеге Регламент һәм капиталь төзелеш объектында контроль чараларын үткәрү тәртибе белән таныштырырга тиеш.

5.75. Төзүче оешма җитәкчесен (ул вәкаләт биргән затны) тикшерү уздыру турында күрсәтмә таныштыру турында тикшерү актында тиешле язу теркәлә.

5.76. Тикшерү уздырганда вазыйфаи зат әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән зарури таләпләрнең үтәлешен тикшерә, моның өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

а) төзелеш алып баручы зат тарафыннан, тикшерү үткәрү өчен тапшырылган эшләрне башкару белән бәйле документларны карый;

б) башкарылган эшләргә визуаль карау үткәрә (кирәк булганда – приборлар кулланып);

в) тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерә;

г) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда административ хокук бозуларга юл куйган затларны административ җаваплылыкка тартуга юнәлдерелгән гамәлләрне башкара.

Әлеге пунктның «а», «б» пунктчаларында каралган гамәлләрнең эзлеклелеге вазыйфаи зат тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: үткәрелгән контрольлек чаралары.

Үтәлү вакыты: 20 эш көненнән артык түгел.

Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерү нәтиҗәләре турында тиешле мәгълүмат «Стройнадзор РТ» мәгълүмат-аналитика системасында, ә юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата шулай ук тикшерүләрнең бердәм реестрында җаваплы башкаручы тарафыннан кертелә.

Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү

5.78. Тикшерүне тәмамлау административ процедураның нигезе булып тора.

5.79. Тикшерү нәтиҗәләре буенча вазыйфаи зат (төркем җитәкчесе) билгеләнгән форма буенча тикшерү актын (әлеге Регламентка 11 нче кушымта) өч нөсхәдә төзи.

Тикшерү актында түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) тикшерү актын төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) Инспекциянең исеме;

3) Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсенең датасы һәм номеры;

4) тикшерү уздырган вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, ата исемнәре, вазыйфалары;

5) тикшерелә торган затның атамасы яисә физик затның фамилиясе, исеме һәм ата исеме, шулай ук тикшерү уздырганда катнашкан юридик зат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, ата исеме һәм вазыйфасы;

6) тикшерү үткәрү датасы, вакыты, озынлыгы һәм урыны;

7) тикшерү нәтиҗәләре турында белешмәләр, шул исәптән зарури таләпләрне бозу, аларның характеры һәм күрсәтелгән бозуларга юл куйган затлар турында белешмәләр;

8) тикшерү уздырганда катнашкан юридик зат җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү акты белән таныштыру турында яисә танышудан баш тартуы турында, аларның имзалары булуы турында яисә имза бирүдән баш тартулары турында белешмәләр, шулай ук уздырылган тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналына язу кертү турында яки юридик затта, шәхси эшкуарда әлеге журналның булмавына бәйле рәвештә мондый язуны теркәү мөмкинлегенең булмавы турында белешмәләр;

9) тикшерүдә катнашкан вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның, экспертларның, эксперт оешмаларының имзалары.

Тикшерү актында өстәмә рәвештә үзенә карата контроль чаралар үткәрелгән капиталь төзелеш объектының исеме һәм урнашу урыны күрсәтелә.

Тикшерү актына беркетмәләр яки үткәрелгән экспертизаларның бәяләмәләре һәм тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яки аларның күчермәләре, шул исәптән фото, видео, кинотасма материаллары, ачыкланган бозуларның дәлилләрен теркәүнең башка билгеләнгән ысул материаллары теркәлә.

Тикшерү актының бер нөсхәсе кушымталарның күчермәләре белән бергә юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә танышып чыгу турында яисә танышып чыгудан баш тарту турында тикшерү актында кул куйдырып тапшырыла. Кушымталарның күчермәләре белән тикшерү актының икенче нөсхәсе күзәтчелек эшенә урнаштырыла һәм билгеләнгән тәртиптә Инспекциядә саклана.

РФ ШрК 54 статьясындагы 6.2 өлешендә күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләренә карата төзүче оешма тарафыннан суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

Юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тарту турында имза куясы килмәсә, вазыйфаи зат (төркем җитәкчесе) акт кулга тапшыру турында белдереп, почта аша заказлы хат итеп җибәрә, кулга алу турындагы белдерү Инспекциянең күзәтчелек эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Тикшерелә торган затның электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы акты төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелүче затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип исәпләнә.

Үтәлү вакыты: актны рәсмиләштерү һәм тапшыру – тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры; актны заказлы почта юлламасы итеп җибәргән очракта – тикшерү тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: тикшерелә торган затка тапшырылган яки тикшерелә торган зат адресына юлланган тикшерү акты.

5.80. Әгәр тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмә алу кирәк булса, тикшерү акты контрольлек чараларын тәмамлаганнан соң өч эш көненнән артып китмәгән чорда төзелә һәм юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка кул куйдыртып тапшырыла яисә кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрелә һәм (яисә)

шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә (тикшерелүче затның дәүләт төзелеш күзәтчелеге кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыруга ризалыгы булган очракта), күрсәтелгән документның алынуын тәэмин итүче ысул белән җиткерелә. Бу вакытта кулга тапшыру турыда белдерү һәм (яисә) күрсәтелгән документның алынуына башкача дәлилләмә тикшерү актының Инспекциядә саклана торган күзәтчелек эшендәге нөсхәсенә теркәп куела.

5.81. Әгәр урынга чыгып тикшерү уздыру өчен аның прокуратура органы белән килештерлүе таләп ителгән булса, вазыйфаи зат (төркем җитәкчесе) тикшерү акты күчермәсен тикшерү уздыруны килештерү турында карарны кабул иткән прокуратура органына җибәрә.

Үтәлү вакыты: тикшерү актын төзегән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.82. Уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча төзелешкә рөхсәт алмыйча капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору факты (капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору өчен мондый рөхсәтне алу таләп ителмәгән очраклардан тыш) яки капиталь төзелеш объектының төзелешкә бирелгән рөхсәттә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү факты ачыкланган очракта, әгәр капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору өчен төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәгән очракта капиталь төзелеш объектының капиталь төзелеш объектларын рөхсәтле төзү, үзгәртеп коруның җирдән файдалану, төзелеш кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән чик параметрларына туры килмәү яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата РФ ШрК, башка федераль законнарда билгеләнгән зарури таләпләргә туры килмәү факты ачыкланган очракта, вазыйфаи зат өч нөсхәдә тикшерү актын төзи; актның өченче нөсхәсен, шулай ук тикшерү уздыру барышында төзелгән яки алынган документларны, үзирекле төзелеш ачыклануы турындагы хәбәрне (әлеге Регламентның 18 нче кушымтасы) теркәп, мондый капиталь төзелеш объекты урнашкан урын буенча җирлекнең, шәһәр округының җирле үзидарә органына яки, капиталь төзелеш объекты җирлекара территориядә урнашкан булса, муниципаль районның җирле үзидарә органына җибәрә. Ирекле төзелеш ачыклау турында хәбәр итү формасы, шулай ук ирекле төзелеш билгеләре булуын ачыклый торган документлар исемлеге Россия Төзелеш министрлыгының 2019 елның 19 мартындагы 169/пр номерлы боерыгы белән билгеләнгән.

Үтәлү вакыты: тикшерү тәмамланган көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: тиешле фактны раслый торган документларны теркәп, үзирекле төзелеш ачыклануы турындагы хәбәрне җирле үзидарә органына җибәрү.

5.83. Административ процедураны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

- өч нөсхәдә рәсмиләштерелгән тикшерү акты;

- тикшерү үткәрү прокуратура органы белән килештерелгән очракта – прокуратура органына җибәрелгән тикшерү акты күчермәсе;

- җирле үзидарә органына җибәрелгән тикшерү актының өченче нөсхәсе, шулай ук, үзирекле төзелеш ачыклануы турында хәбәр итеп, тикшерү уздыру

процессында төзелгән яки алынган документлар.

«Әлеге Регламентның 1.4 пунктының «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерүне гамәлгә ашыру» административ процедурасы нәтиҗәләре турында тиешле мәгълүмат «ТР Төзелеш күзәтчелеге» МАС системасында җаваплы башкаручы тарафыннан формалаштырыла, Тикшерүләрнең бердәм реестрына белешмәләр 294-ФЗ номерлы федераль законның $13^3$ статьясында һәм РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карарында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан кертелә. Тикшерүләрнең бердәм реестры сайтына сылтама Инспекциянең рәсми сайтында «Дәүләт күзәтчелеге (контроль)» бүлегендә урнашкан.»;

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге*

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгы;

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгының беренче урынбасары;

3. Инспекциянең территориаль органнары җитәкчеләре һәм җитәкчеләрнең урынбасарлары;

4. Инспекциянең территориаль органнары бүлекләре башлыклары;

5. Консультантлар, әйдәп баручы белгечләр – экспертлар, 2 разрядлы өлкән белгечләр, 3 разрядлы өлкән белгечләр, өлкән белгечләр, 1 категория белгечләре.

* Исемлектә күрсәтелгән Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе вазыйфаи затлары Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 28.3 статьясы, асылда 6.3, 8.1, 9.4, 9.5, 9.5.1 статьялар (капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә) буенча, Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 9.16 статьясының 3 өлеше, 14.44 статьясы, 19.4 статьясының 1 өлеше, 19.4.1 статьясы, 19.5 статьясының 6 һәм 15 өлешләре, 19.6, 19.7 һәм 19.33 статьялары, 20.4 статьясының 1, 2, 6, 6.1 һәм 9 өлешләре, 20.25 статьясының 1 өлеше буенча беркетмәләр төзергә хокуклы.»;

Регламентка 2 нче кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентның 1.4 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән объектларга карата Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы»;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына № $2^1$ **кушымта**

Әлеге Регламентның 1.4 пунктының «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы

Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерүне оештыру һәм әзерләү

Мөрәҗәгатьне кабул итү, теркәү, карау (законнарда билгеләнгән срокларда)

Күзәтчелек эшен формалаштыру

Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерүне әзерләү һәм уздыру

Ведомствоара һәм башка мөрәҗәгатьләр җибәрү, кирәк булганда экспертларны (эксперт оешмаларын) җәлеп итү

Тикшерү уздыру турында күрсәтмә әзерләү (тикшерү уздыра башларга кимендә дүрт эш көне кала)

Тикшерелә торган затка тикшерү уздыру турында хәбәр итү (тикшерүне үткәрә башларга кимендә өч эш көненнән дә соңга калмыйча)

Күрсәтмә нигезендә (егерме эш көненнән дә артык түгел) күчмә тикшерү үткәрү

Әлеге Регламентның 1.4 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата күчмә тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү

Тикшерелүче затны тикшерү акты белән таныштыру (тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры)

Тикшерү акты күчермәсен прокуратура органына җибәрү (прокуратура органы белән килешенгәнлек булганда) (тикшерү тәмамлангач биш эш көне эчендә)

Үзирекле төзелешне ачыклау турында хәбәр җирле үзидарә органнарына җибәрү (тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә)

Зарури таләпләр бозылуы ачыкланганда – Административ хокук бозулар турында РФ кодексы буенча чаралар

түбәндәге эчтәлекле 18 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелеш күзәтчелеге
инспекциясе тарафыннан
Татарстан Республикасында
төбәк дәүләт төзелеш
күзәтчелеген гамәлгә ашыру
буенча дәүләт функциясен
үтәүнең административ
регламентына 18 нче кушымта

РӘВЕШЕ
(Россия Федерациясе Төзелеш
һәм торак-коммуналь хуҗалык
министрлыгының «Үзирекле
төзелешне ачыклау турында
хәбәр формасын һәм үзирекле
төзелеш билгеләре булуын
раслый торган документлар
исемлеген раслау турында» 2019
елның 19 мартындагы 169/пр
номерлы боерыгы белән
расланган)

№_________________ «__»__________ 20_ ел.

Үзирекле корылманы ачыклау турында
белдерү

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән дәүләт хакимиятенең башкарма органы, вазыйфаи зат, дәүләт учреждениесе яисә җирле үзидарә органы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1, 16 статья, 2018, № 32, 5133, 5135 ст.)

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(почта адресы һәм (яки) элемтә өчен электрон почта адресы)

хәбәр итә_________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________,

(үзирекле корылма урнашкан урын буенча җирле үзидарә органы, яки, үзирекле корылма җирлекара территориядә урнашкан очракта, муниципаль районның җирле үзидарә органы)

_____________________ уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча

(тикшерү үткәрү датасы)

әлеге җир кишәрлегендә___________________________________________________,

(кадастр номеры (булганда)

урнашкан__________________________________________________________________,

_______________________________________________________________________________

(җир кишәрлегенең адресы яки урыны)

ачыкланды:
1. Бина, корылма яки башка бина төзү (булдыру) факты____________________________________
_____________________________________________________________________________
(билгеләнгән тәртиптә бирелмәгән җир кишәрлегендә бинаны, корылманы яки башка корылманы билгеләү, кадастр номеры (булган очракта), бу тикшерү акты белән раслана_____________________________________________________________________
____________________________________________________________________________.*
(тикшерү акты турында мәгълүмат)
2. Бина, корылма яки башка бина торгызу (булдыру) факты_________________________________
____________________________________________________________________________,
(рөхсәтле файдалану әлеге объектны төзергә рөхсәт итми торган җир кишәрлегендә бинаны, корылманы яки башка корылманы билгеләү, кадастр номеры (булганда), бу тикшерү акты белән раслана_____________________________________________________________________
____________________________________________________________________________.*
(тикшерү акты турында мәгълүмат)
3. Бина, корылма яки башка бинаны торгызу (төзү) факты__________________________________
_____________________________________________________________________________
(бинаны, корылманы яки башка корылманы билгеләү, кадастр номеры (булганда), закон нигезендә кирәкле килешүләр, рөхсәтләр алмыйча, моны тикшерү акты белән раслау
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________.*
(тикшерү акты турында мәгълүмат)
4. Бина, корылма яки башка бинаны торгызу (төзү) факты__________________________________
____________________________________________________________________________
(шәһәр төзелеше һәм төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре бозылган бинаны, корылманы яки башка корылманы билгеләү, кадастр номеры (булган очракта), бу тикшерү акты белән раслана__________________________________________________________________
____________________________________________________________________________.*
(тикшерү акты турында мәгълүмат)
Кушымта:_____________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 222 статьясының 1 пунктында каралган үзирекле төзелеш билгеләренең булуын раслаучы документлар (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1994, № 32, 3301; 2006, № 27, 2881; 2015, № 29, 4384; 2018, № 32, 5132 ст)

______________________ ______________________ ______________________
(вәкаләтле зат) (имза) (тулы имза)

М.У.
(булган очракта)

* Ачыкланган факт булганда тутырыла.

Үзирекле корылма билгеләре булуны раслаучы документлар

исемлеге

1. «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясында билгеләнгән тәртиптә «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик

затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән (Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2010 елның 24 маендагы 199 номерлы, 2011 елның 30 сентябрендәге 532 номерлы, 2016 елның 30 сентябрендәге 620 номерлы боерыклары керткән үзгәрешләре белән) билгеләнгән форма буенча тикшерү акты.

2. Россия Федерациясе Җир кодексының 71 статьясындагы 7 пунктында күрсәтелгән тикшерү акты.

3. Россия Федерациясе Җир кодексының 72 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән тикшерү акты.

4. Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган, электрон документ формасында яки документ күчермәсе рәвешендә кәгазь документ формасында яки «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законның 62 статьясы нигезендә билгеләнгән башка рәвештә тапшырылган, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына мәгълүматлар кертүгә нигез булган белешмәләр, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр.».